**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Россия Көнен һәм Татарстан Республикасы Көнен бәйрәм итүгә багышланган чараларны әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Россия Көнен һәм Татарстан Республикасы Көнен бәйрәм итүгә багышланган чараларны әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитетын төзү турында» 2017 елның 26 маендагы ПУ-441 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2017 елның 22 декабрендәге ПУ-1153 номерлы, 2018 елның 19 февралендәге ПУ-177 номерлы, 2018 елның 6 июнендәге ПУ-406 номерлы, 2018 елның 21 сентябрендәге ПУ-678 номерлы һәм 2020 елның 26 февралендәге ПУ-120 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Россия Көнен һәм Татарстан Республикасы Көнен бәйрәм итүгә багышланган чараларны әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) оештыру комитеты составыннан Р.Т. Борһановны, Н.М. Владимировны, Р.З. Закировны чыгарырга;

б) оештыру комитеты составына кертергә:

Һадиуллин Илсур Гәрәй улын – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрын;

Шакиров Данис Фәнис улын – Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесен (килешү буенча);

Яковлев Константин Геннадиевичны – Татарстан халыклары ассамблеясе советы рәисе урынбасары – Татарстан халыклары ассамблеясе советы Башкарма комитеты җитәкчесен (килешү буенча);

в) оештыру комитеты әгъзасы М.Р. Шаһиәхмәтовның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын башкаручы** **А.В. Песошин**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 12 март
№ ПУ-233